

ISSN 0868-4545

Салават күпере





Габдулла ТУКАЙ

Көзге һәм маймыл

Маймыл Көзгедән үзенең сурәтен күргәч, әкрен генә, янындагы Аюга аягы белән төртеп:

"Кара әле, иптәш! Көзгедә нинди кыяфәтсез, нинди ямьсез бер хайван күренә. Кара әле, йөзе нинди килешсез! Әгәр мин шул Көзгедә күренгән нәрсәгә аз гына охшасам да, хәсрәтемнән буылып үләр идем.

Хәер, әйтергә мөмкин, минем иптәш вә дусларым арасында да бу Көзгедә күренгән хайван төсле ямьсезләр биш-алтылап бар, хәтта мин аларны бармак берлән санап күрсәтә алам", – диде.

Аю моңар җавапта:

"И Маймыл иптәш! Син иптәш вә дусларыңны санап мәшәкатьләнгәнче, бер мәртәбә үзеңә генә карасаң булмасмы?" – диде.



© "Салават күпере", 1998 ел

Сәмига СӘҮБАНОВА

Бабай түбәтәе



Бер бабай болында печән чаба икән.

Шунда аның борынына күбәләк килеп кунган. Күбәләкне куркытмас өчен бабай чалгысына таянып тын калган. Тик күбәләк тиз генә очып китәргә уйламаган. Аның очканын көтә торгач, бабай йоклап киткән. Шунда аның түбәтәенә бер кош оя ясаган, йомырка салган, бала чыгарган. Алар үскәннәр, ояны тарсынып кыбырсый башлаганнар һәм аска карап:

– Нинди биектә икән безнең оябыз, егылып төшсәк, чәлпәрәмә киләбез, – дип, куркышып, бер-берсенә ныграк сыенышканнар.

Ул арада бабай уянган, төчкереп җибәргән, борынындагы күбәләк куркуыннан очып киткән. Бабай чалгысын селтәнә башлаган.

Түбәтәендәге кошлар:

– Көчле давыл чыкты, – дип, тагын да ныграк куркышканнар.

Чалгысын селтәнә торгач, карт маңгаеның тирен сөртмәкче булып, кульяулык эзләгән, тапмагач, түбәтәен салган.

Салуы булган, кош балалары очып киткәннәр. Бабай, маңгай тирен кул арты белән сөртә-сөртә, аларга хәерле юл теләп, түбәтәен болгап калган.

Рәссам Сергей АНДРИАНОВ

Рөстәм МИНГАЛИМ

Ике малай, алты ачкыч һәм җиде чемодан

Өйләренә бик якында –
авыл артында
ике малай уйнаган.
... Карасалар... Ни күрә болар?!
Ни күрә болар берзаман?!
Каршыларында
ята икән
чемодан,
авыр чемодан.

– Ах, моны ачарга иде?! –

Ачкычлары юк.
Малайлар –
көне буе хыялланганнар:
– Ах, моны ачарга?!
... Кичке якта
карт ала карга
алты ачкыч
ташлап киткән малайларга.

Авыр чемоданны иплəп кенә
ачканнар малайлар икәү.
Тик чемодан эчендә –
тагын чемодан икән.
Аны да ачканнар –
тагын чемодан икән.
Аны да ачсалар –
тагын чемодан?!
...Шулай
ача-ача
алты ачкыч белән
алты чемодан ачкач –
малайларның
ачкычлары беткән:
– Уф, алтынчы эчендә –
җиденче чемодан?!

Җиденче чемодан –
бикләнмәгән булган,
чөнки эчендә берни дә булмаган.



шигырьләре



Алмалы күлмәк

Бу хакта –
язып бетереп булмас
һәм бетереп булмас сөйләп:
никтер Рузиягә һаман
бирәләр дә бирәләр
югала торган бүләк.
Югалган бүләкне эзләп
Рузия
көн дә өйне пыр туздыра,
үзе дә пыр туза.
Өй туздыруда Рузия –
дөньяның
бөтен Рузиясен уза.
Хәтта үзенең
ала песиен уза.
...Әле бүген дә эзләде-эзләде,
табылмый аның
түшенә алма чигелгән
күлмәге.

Алмалы күлмәк –
апасының бүләге!
Шул югалды!
Әллә шайтан алды?
Инде Рузия аптырап,
түрбүлмәдә – зур бүлмәдә,
идәннең нәкъ уртасында
кайгырып утыра.
Тирә-юнենә сибелгән
кәгазьләр, киемнәр.
Ята әнә – ике юрган,
биш мендәр,
алты уенчык,
тагын әллә ниләр...
...Икенче бүлмәдән
ала песи килә.
Авызында –
алмалы күлмәк!
Мырлап килә песи:
– Мыр-р-р, мыр-р-р,
Р-р-рузиягә
ник бир-р-р-рәсез, – ди, –
югала торган бүләк?!

Рәссам Светлана ЯРКОВА

Зөһрә кыз

Ләбиб Лерон шигыре
Фәннур Галимов көе

Төнбоеклы төнге күлдә
Сары көймә-ай йөзә.
Ул көймәдә Зөһрә гүзәл –
Бигрәк нурлы, һай, йөзе!
(Соңгы ике юл 2 мәртәбә кабатлана)

Кушымта:
Инҗәсендә көянтәсе,
Көянтәдә – чиләкләр.
Зөһрә кызның күңелендә
Нинди уйлар, теләкләр?
(Кушымта 2 мәртәбә кабатлана).

Төнге күлдә тынып калган
Көндезге шау, чыр-чулар...
Зөһрә гүзәл, суга карап,
Салмак кына җыр суза:

Кушымта:
Ай-көймәмдә төн дә йөзәм —
Серләрен күл ачмасмы?
Йөрәктәге сагышларны
Төнге сулар басмасмы?..

Andantino.

Gm Eb F7 B
Төн – бо – ек – лы төн – ге – күл – дә
F7 Eb D7 Gm
Са – ры көй – мә — ай йө – зә...
F7 B
Ул көй – мә – дә Зөһ – рә гү – зәл
F7 Eb D7 Gm
Биг – рәк нур – лы, һай, йө – зе.
Gm Cm Gm
Иң – сә – сен – дә кө – ян – тә – се,
Gm Cm Gm
Кө – ян – тә – дә чи – ләк – ләр
F7 B D7 Gm
Зө – (һе) – рә кыз – ның кү – ңе – лен – дә
F7 B D7 Gm
Нин – ди уй – лар, те – ләк – ләр?



Нәкыйп КАШТАНОВ

Табышмак

Әле сөйли,
Әле көйли,
Әле җырлый,
Әле чыжлый.
Биемичә
Көчкә түзеп
Торам дия,
Сез, балалар,
Ду куптартып
Биесәгез
Мин дә биим
Ди...

(радио)





Санамыш

Берәү, икәү...
Мияу да мияубикәү.
Камка түткәй,
Сары түшкәй —
Песнәк.
Черки—тешләк.
Төнге Ай.
Акбай.
Юртак тай!

Рәссам Светлана ИБРАҺИМОВА



Бәхет

Әкият

Бәхет өйдән өйгә кунакка йөри.

Ул тырыш, яхшы күңелле, дуслары күп булган кешеләрдә озаграк тора. Дуслары булмаган, әшәке, комсыз кешеләрдә озак тормый — тиз китә. Ялкауларны да ул яратмый.

Кайбер өйләргә бәхет хайваннар белән ияреп килә. Бәхетнең килүен беренче булып әтәч хәбәр итә. Бәхет йорт хайваннарын яраткан кешеләргә еш килә. Ул биек йортларда лифтка утырып менми, ә үзе лифт шикелле күтәрелә. Ул тирә-юньне яктылыкка күмеп, йомшак кына өскә атлый.

Ул балыклар шикелле аквариум эчендә яши алмый, чөнки суда эреп юкка чыгуыннан курка. Шуңа күрә аквариум янында яши. Ул урамда яки йортларда кояштай сары була, ә фатирда инде тыныч төскә керә һәм күзгә бәрелеп тормый. Ул төнлә өйдә йоклый һәм өйне явыз кешеләрдән саклый. Тәмле әйберләр пешергәнне ярата. Бигрәк тә өчпочмак һәм пилмәнне. Тик менә «Сникерс»ны нигәдер яратмый.

Бәхет кешеләргә һәр эштә булыша.

Эльвина Ибәтуллина,
8 яшь. Казан.





Ибраһимова Эльвира рәсемнәре. (7 яшь).
Кукмара, Зур Сәрдек.

Эльмира Шәрифуллина язган китаплар

Безнең зоопарк	1976
Яңгыр җиле	1984
Мизгел	1986
Гөлләр елы	1988
Җитәкләшеп җил белән	1990
Зәңгәр эңгер	1991


Рәссам Диләрә Нәүрузова

Кадерле дускай!

Журналның урта битен иплəп кенə алып, кара сызыклар буенча кисегез, сары сызыклар буенча бөклəгез дə, килеп чыккан кисəклəрне, бит саннарына карап, китап итеп җыегыз. Булгач-булгач чын китап булсын — уртасын ике урыннан төплəп тə куегыз.



«Салават күпере» китапханәсе



Кем ул?

Үтеп барышлый сикереп
Менә печән йөгенә.
Көтүдән кайтмый йөдәтә,
Төшә күпер төбенә.

Мур кыргыры, дип куасың,
Сакалын да селкетми.
Бар эше бурлык булса да,
Бур, дигән сүз өркетми.

Сөте, мае бик сихәтле,
Мамыгы шәлгә әйбәт.
Уйлагыз әле, балалар,
Кем турында бу гайбәт?

(кәҗә)





Әкиятләр яратам

Әкиятләр нинди була?
Әкиятләр батырлар:
Бар бит анда ак аюлар,
Көчле Камыр Батырлар.

Әкиятләр нинди була?
Әкиятләр шаяннар:
Йөгерешә Җилаяклар,
Чакмый торган Чаяннар.


Әкиятләр нинди була?
Әкиятләр хәйләле:
Чөнки анда зирәк Былтыр,
Тагын елак Шүрәле...


Серле, кызык әкиятләрне
Тыңларга бик яратам.
Әкият сөйли дә әтием,
Шундук йокларга ятам.

Зәңгәр күлмәкле Зилә

Бакчабыз тулы чәчәкләр,
Бигрәк күп зәңгәрләре.
Аларны үстерер өчен
Зилә көч жәлләмәде.

Су сибәргә чыкканда да
Зәңгәр күлмәген кия.
Ахры, Зилә чәчәкләрнең
Күзе төслесен сөя.





Кояшлы уен

Яуды яңгыр, яуды яңгыр,
Күлләвекләр җыелды.
Чулт-чулт итеп агачлардан
Шук тамчылар коелды.

Шатлыгыннан кош сайрады,
Кояш чыкты ялтырап.
Ап-ак томан җиргә ятты,
Җиргә ятты ял сорап.

Әнә, салават күпере —
Ал, кызыл басмалары.
Әйтерсең, нәни кызларның
Чәчүргеч тасмалары.

Уянды бөтен табигать,
Гөлләр нурга коенды.
Гүя, яңгыр башлап китте
Бу кояшлы уенны.

Яңа бәби

Яңа бәби алып кайтты
Әни базардан.
Күрше-күлән кереп тулды
Бәби карарга.

Кергәннәргә күрсәтәләр
Бары тәпиен.
«Юкса күз тидерерсез», — дип,
Көлә әбием.

Дәү үссен дә, таза булсын,
Бик матур, имеш.
Мактаган булалар тагы
Күрмәгән килеш.

Ничек итсәм, иттем әле,
Хәйләсен таптым,
Кеше югында биләвен
Чиштем дә — бактым.

Шаккатмалы икән чынлап,
Нәни аяк-кул.
Бәбиебез сокланырлык
Матур икән шул!



Әкият кайда?

Сихри алан, гүзәл алан,
Күк печән күбәләре.
Урман шаулый, агачларның
Күктә күк түбәләре.

Кыштырдый камыл төбендә
Кыл күтәргән кырмыска.
Хәтта шул нәни кырмыска
Ямь өсти бу тормышка.

Төреп алган моң, могҗиза,
Сер сөялгән имәнгә.
Нинди җан соң сихерләнми,
Урман, сиңа килгәндә?

Йөрим, йөгерәм, туктап калам,
Сискәнеп китә күңел.
Әкият борын төбендә,
Борын-борында түгел.





Үзебез дә гөлләр кебек

Гөлләремә сулар сибәм —
Сулышлары киңәйсен.
Якты көн, кояш алдында
Чәчәк атсын, ирәйсен.

Чәчәк атсыннар гөлләрем
Өемдәге һәркемгә.
Бер бөтен гаилә булып,
Яшәргә язсын безгә.

Чәчәк кебек якты булып
Ачылсын күңелебез.
Бер савытта үскән гөл күк —
Карасаң һәрберебез.

Шигъри табышмак — җавабын табып бак!

Ринат НУРУЛЛИН

Үрдәк керде төшемә

Төшемдә үрдәк күрсәм дә,
Казлар турында сүзем.
Табышмакны сезгә сөйлим
Чишә алмагач үзем.

... Казлар төшә күл буена
Чылбырдай тезелешеп.
Икешәр каз уртасында
Сукмактан атлый берсе.

Бер ата каз алда бара,
Әйтерсең лә генерал.
Шул ата казның артыннан
Дүртесе титаклыйлар.

Соңгы казның алдыннан ук
Дүрт каз килә иң элек.
Ничә каз бара сукмактан
Җепкә күмәк тезелеп?



Кем нәрсә ярата

Татар халык әкияте

Бер йортта Песи белән Эт, Әтәч белән Кәҗә яшәгәннәр. Кич белән алар ишек төбенә җыелалар да үзләренең эшләре турында сөйләшәләр икән. Сөйләшәләр дә бәхәсләшеп тә китәләр икән. Кем нәрсә ярата? Нинди азык тәмлерәк? – дип бәхәсләшәләр икән.

– Иң тәмле сый – сөт, – ди Песи. – Сөттән соң бер тычкан да тотып кабып җибәрсәң, бигрәк тә шәп була инде. Тик тычканны тотуы кыен.

– Сөт нәрсә? Ул бик сыек, тамак туйдырмый. Ә менә ярма бөртекләрен, солы орлыгын тук-тук итеп чүпләсәң – менә шунда тамак тук-тук-тук була, – ди Әтәч.


– Юк, юк, – дип сүзгә кушыла Акбай. – Бөртек чүпләп кенә туеп бул-бул-булмый. Менә сөяк кимерсәң, чынлап та әйбәт була, шунда ук тук буласың. Нинди азык тәмле, нинди азык файдалы икәнен миннән дә әйбәт белгән хайван юк.

– Нәрсә-ә-ә-ә сөйлисең син, – дип каршы килә Кәҗә. – Менә кәбестә-ә-ә булса икән. Иң тәмле азык – кәбестә-ә-ә, – ди ул.

Алар бәхәсләшәләр дә бәхәсләшәләр икән – әле һаман килешә алганнары юк икән.



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ





Болытның сусыл күләгәсе

Бал корты сап-сары көнбагышка килеп кунды. Алдануын белгәч, чәчрәп читкә китте. Аны күзәтеп торган малайлар-кызлар көлеп җибәрделәр. Көнбагыш-айбагарлар рәсем генә ләбаса! Рәсем укытучысы Вәгыйз Камалетдинов шундый да оста ясый аларны, хәтта бал кортлары да алданалар.

Чувашиянең Комсомол районы Урмай авылы мәктәбендә шундый бәхетле балалар укый. Алар матурлыкны сабый чактан ук танырга өйрәнәләр, кулларына каләм, пумала тотып рәсем ясау серләренә төшенәләр. Яшькелт урманнар, кабарып торган алсу болытлар кәгазьләргә, тукымаларга төшә. Менә Вәгыйз абыйлары берәрсен төзәтеп җибәрә: «Болыт күләгәсе менә бу яккарак кыйшаеп тора», - ди. Шунда ук җиләс җил исеп киткәндәй була, яңгыр исе мәктәпкә тарала.

Дәрестән соң алар Вәгыйз абыйның остаханәсенә баралар. Анда әзер картиналар арасында төгәлләнмәгәннәре дә бар. Остаз кулына пумала ала. Бер селтәнүгә үк бүлмә тагын да нурланып китә. Ул язган бөтен картиналар да монда түгел әле, аларның кайсыберләре Казанда, Чабаксарда, Мәскәүдә, Һамбургта, Вильнюста саклана. Бу калаларга да Урмай өстендәге болытның сусыл күләгәсе төшкән.

Ркаил Зәйдулла







Әлеге рәсемнәрдәге матур малайлар менә-менә урыннарыннан кузгалырлар да уйнарга чыгып йөгерерләр сыман...

Таныш булыгыз:

Азалия



Азалия Чаллы кызы, аңа 5 яшь. 1997 елның «Таң йолдызы» республика бәйгесе лауреаты. Шушы ук елны ул «Җырлыйсым килә» дип аталган икенче бәйгедә «Гран-При» бүләгенә дә лаек булды.

Азалия Костина белән без моннан ике ел элек Чаллыда, концерт залында танышкан идек. Үзенең гаҗәеп мөлаемлелеге, матур, моңлы тавышы, чын артистларга хас сәхнә хәрәкәте белән үзенә җәлеп итте ул мине, дөресрәге, сихерләде.

— Читекләрең бигрәк матур, каян алдыгыз? — дип сорыйм.

— Әтием Арчадан махсус заказ белән тектереп алып кайтты.

Чигүле күлмәгенә күз төшерәм, бигрәк тере чәчәкләр инде.

— Күлмәгемне әтием белән әнием бергәләп тектереп алдылар. — Калфагым килешәме соң? — дип сорап куя Азалия.

— Искиткеч матур,— дим мин. — Энҗе-мәрҗәннәре күз явын алырлык. Шулай матур итеп җырларга кем өйрәтә соң сине, Азалия?

— Әнием инде. Әтием дә булыша бераз. Ул күбрәк акча табу ягын карый. Миңа яңа күлмәкләр яздыру өчен күп акча кирәк ич. Әле минем беренче сыйныфта укый торган абыем да бар. Әтием миңа кечкенә синтезатор да бүләк итте. Мине бигрәк тә ярата ул.

— Дүрт яшьтә «Гран-При» бүләгенә ия булу өчен ничә яшьтән җырлый башларга кирәк соң?

— Мин сөйләшә белә башлаганнан бирле җырлыйм инде. Ике яшь тулыр-тулмастан җырларны отып, магнитофонга ияреп җырлаганмын. Әнием шулай ди.

— Сәхнә хәрәкәтенә каян өйрәндең?

— Безнең Чаллыда концертлар еш булып тора. Ә без гаиләбез белән концертларга еш йөрибез. Концерт караганда да залда җырчы апаларга ияреп биим. Өйдә дә көзге каршында боргаланырга яратам. Шулай өйрәнәм инде.

Азалия быел Илбашының Чыршы бәйрәмендә Кыш бабайның үзе белән биеп җырлады. Болар әле җыр сәнгатенә алып чыгучы чишмә башы гына. Мин ышанам, егерме беренче гасырда сәхнә йолдызы булып танылыр әле безнең Азалиябез. Әйдәгез, без аңа иҗади уңышлар, бәхетле балачак һәм хыялларының тормышка ашуын телик. Ак юл сиңа, нәни җырчы, гүзәл кыз, Азалия!

Дания Гайнетдинова

Роза Кожевникова шигырьләре

Шыгырдавык

Шыгырдавык кайда яши?
Карда яши — мин беләм!
Мин урамга чыгуга ук
Исәнләшә ул гелән.

Бакчага хәтле илтә ул,
Бакчадан — өйгә чаклы.
Шыгыр-шыгыр шигырь сөйли...
Миңа да ятлатмакчы!..





Тапкыр

Бүләккә әфлисун бирделәр —
Нибары бер генә...
Азын аз... Шулай да борчылып
Тормадым мин менә! —
«Әфлисун күп булса әйбәт тә...
Булмагач нишлим соң?» —
Дидем дә... Куйдым мин бүлгәләп —
Күбәйде әфлисун!..

Рәссам Юлия ЩЕТИНКИНА

Тавыш

Минем тавыш яши
Авызым эчендә.
Бер дә тынып тормый -
Тынгы юк һич кенә.
Кызлар сыман елый,
Малайлардай көлә.
Дәшмим дигәндә дә
Күп сөйләшә белә.

Сөт

Сүземә ышансаң,
Көт син, көт:
Кайнарга куркудан
Савыттан кача сөт.



Урысчадан **Ләбиб Лерон** һәм **Ләис Зөлкарнәй** тәрҗемә кылды.

Салават күпере

6(100) - 1998

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГЪЛҮМАТ ҺӘМ МАТБУГАТ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ
1990 елның март аеннан бирле чыга

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства информации и печати РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке.
Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары - җаваплы сәркатип
Фирая БӘДРЕТДИН

Бүлек мөхәррире
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
Светлана ПРИВИНА рәсемнәре

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Производствога бирелде 29.05.98 ел.
Басарга кул куелды 29.05.98 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Басма табак 1,5 (2,1).
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 19350 данә. Заказ Я-262.
Бәясе килешү буенча.

POINT

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Энҗе бөртекләре

Лилия Нигъмәтова шигыре
Наилә Яхина көе



Гамьсез балачагыбыз,
Уйныйбыз да көләбез.
Төштә могҗиза күреп,
Хыялланып үсәбез.

Кушымта:
Энҗе, энҗе бөртекләре —
без ул, без ул бөртекләр.
Энҗе, энҗе бөртекләре —
без бит сезнең өметләр.

Залимлекләрдән сакла,
Пәкь күңлебезне какма.
Калма битараф булып,
И Ходам, сакла, сакла.

Кушымта.

Кояшлы булсын көннәр,
Нурлары аның дәва.
Җәен, көзен, кышын, язын
Гел якты булсын дөнья.

Кушымта.

Бу җырны авторлар Казандагы «Энҗекәй» балалар бакчасында тәрбияләнүчеләргә багышлыйлар.



